*булуын күрмәссез»,* - дигән (Бәйһәкый).

Ислам динендә кайбер хәлләрдә ялганларга рөхсәт ителә:

– бер-берсе белән сөйләшмәгән ир белән хатынны яки ике мөселманны килештерер өчен;

– сугышта дошманны алдар өчен;

– кемнең булса да җанына, малына, диненә һәм намусына золым һәм хаксызлык белән зарар килгәндә, аларны коткарыр өчен;

– хаста кешеләргә өмет һәм яшәү көче бирер өчен.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм бер хәдисендә шулай дигән: *«Халыкның арасын төзәтер өчен, изге максат белән сүз йөрткән яки изге ният белән ялган сөйләгән кеше ялганчы түгелдер».*

Габдулла бин Гамр (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде) риваять итә: *«Беркөнне Пәйгамбәребез галәйһиссәләм янына бәдәви (күчмә гарәп) килә һәм сорау бирә: «Йә рәсүлуллаһ, нинди гөнаһлар зур булып санала?» «Аллаһы Тәгаләгә ширек кылу», - дип җавап бирә Рәсүл Әкрам галәйһиссәләм. «Аннан соң?» - дип сорый бәдәви. «Ата-анага итагатьсезлек, хөрмәтсезлек», – дип әйтә Пәйгамбәребез галәйһиссәләм. «Ә аннан соң?» - дип сорый бәдәви. «Ялган ант», - дип әйтә Аллаһының рәсүле галәйһиссәләм. «Ә ялган антны ничек аңларга соң?» - дип сорый бәдәви. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм болай дип аңлата: «Ялган ант - ул мөселманның малына кызыгып, аның бер өлешен алу өчен ялган ант бирү», - ди* (Бохари).

Бу хәдистә әйтелгәнчә, чит кешенең малына ия булыр өчен бирелгән ялган ант зур гөнаһларның берсе булып санала. Мондый антны биргән кеше хәрәмне хәләл итеп, ялгышлыкны хакыйкать итеп күрсәтә, ягъни исламның төп хөкемнәрен үзгәртә. Шуңа күрә ялган ант кешене башта бу дөньяда гөнаһларга батыра, аннары киләсе дөньяда җәһәннәмгә илтә.

Мөхтәрәм мөселманнар! Телебезне ялганнан һәм башка начар, гөнаһлы сүзләрдән саклар өчен түбәндәге хәдисләрне истә тотыйк.

Әбү Һөрәйрәдән (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде) риваять ителә: Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйткән: *«Аллаһы Тәгаләгә һәм Кыямәт көненә ышанган кеше файдалы, изге сүзләр сөйләсен яки дәшмичә торсын».*

Икенче хәдистә болай дип әйтелгән: *«Тугрылыкны нык саклагыз, тотыгыз, чөнки тугрылык кешене яхшылыкка, яхшылык җәннәткә илтер. Кеше һәрвакыт тугры сөйләсә, Аллаһы янында бик тугры кеше дип языла. Ялганнан сакланыгыз, чөнки ялган начарлыкка, начарлык кешене җәһәннәмгә илтер. Кеше дәвамлы ялган сөйләсә, Аллаһы янында ялганчы дип языла».* (Бохари, Мөслим).

Танылган ислам галиме имам Шәфигый (Аллаһы Тәгалә аны үзенең рәхмәтеннән аермаса иде) әйтте: *«Кеше фикерен белгертеп, сөйләр алдыннан башта бик нык уйласын. Әгәр әйтәчәк сүзләрдә файда булса - сөйләсен. Әгәр шикле булса - сөйләмәсен»,* - диде.

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә барчабызга телләребезне ялганнан, гайбәттән һәм башка Аллаһының ачуын китерә торган сүзләрдән саклап, күбрәк файдалы, изге сүзләрне сөйләргә, Аллаһыны һәрдаим зекер итәргә насыйп итсә иде.

**Нияз хәзрәт САБИРОВ,**
**Мәрҗани мәчете имам-хатыйбы.**

*("Иман" газетасыннан)*

# Татуировка тыела!

Хәзерге заманның танылган галиме, Кувәйт университеты профессоры Мөхәммәд ибн Габделгаффар әш-Шәриф фәтвасыннан Кувәйтнең ислам хокукы энциклопедиясендә болай диелгән: «Татуировка (әл-вашм) – тән тиресен кан чыгарлык итеп энә белән тишү һәм анда тире катламының төсен үзгәртү өчен буяу кертү».

Күпчелек факыйһләр фикеренчә, татуировкалар ясау тыела, моны дөрес, ышанычлы хәдисләр дә раслый, чөнки әлеге хәдисләрдә шушы эшне башкаручы гына түгел, ә аларны үз тәненә ясатучы да каһәрләнә. Бу хәдисләрнең берсе – Ибн Гомәр хәдисе: *«Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм чәчне ялгап үстерү белән шөгыльләнүчеләрне һәм үз чәчен ялгатып үстерүчеләрне, татуировка ясаучыларны һәм татуировка ясатучыларны каһәрләгән».*

Мәликиләр мәзһәбендәге кайбер галимнәр татуировка ясатуны хупланмаган гамәл дип саный. Ән-Нәфрави болай дигән: «Бу эшне (татуировка ясатуны) тыелган (хәрәм) гамәлгә якын хупланмаган гамәл дип санарга була». Кайбер галимнәр исә тыюларга карата искәрмәләр дә керткәннәр, бу татуировканы билгеле бер дәвалану максатында ясаган очракларга кагыла. Әлеге максатларда татуировка ясау рөхсәт ителә, чөнки зарурлык тыелган гамәлне рөхсәт ителгән гамәлгә әйләндерә.

## Татуировка нәҗес булып саналамы һәм аннан ничек арынырга?

Факыйһләр татуировканы нәҗескә саный, чөнки татуировка ясалган урында тән тиресе астына кертелгән нәрсә, ягъни буяу белән бергә кан да тотылып кала.

Татуировкадан ничек арынуга карата галимнәр арасында төрле бәхәсләр, каршылыклар яшәп килә. Хәнәфиләр мәзһәбендәге галимнәр фикеренчә, татуировканы да нәҗес буялган урынны юган кебек чистартырга кирәк. Татуировканың эзе калуга да карамастан, юганнан соң тән тиресе чистара. Тән тиресен салдырырга кирәкми, чөнки бу эзне бетерү бик авыр. Юынганнан соң, кешенең намазы кабул була, һәм ул намазда имам була ала.

Мәликиләр мәзһәбендәге галимнәр әй-



һәм бәхетсез итүдән тора. һәм шуңа охшаш тагы бик күп гөнаһ җимешләре турында сөйләп була. Гөнаһ эшләргә теләгән бәндә аларны иң алдан акыл бизмәненә куеп үлчи белергә тиеш. Кешеләр эшләргә теләгән гөнаһын акыл бизмәненә куеп үлчәгәннән соң, әгәр дә ул гөнаһтан барлыкка килә торган кечкенә генә файда кешене мәңгелек бәхеттән һәм мизанга куеп үлчи алмый торган файдадан ерак итә икән, акыллы кеше ул гөнаһлы фикерен һәм эшен аяк астына салып таптарга һәм юк итәргә тиеш.

Әй, сөекле дустым! Көннәрнең бер көнендә күңелеңдә гөнаһ фикерләре уянса, гөнаһ «орлыклары»н кулыңа тотып, аларны чәчәр өчен гомер бакчаңа чыксаң, ул гөнаһ «орлыклары»нда үкенеч, хәсрәт җимешләрен күрергә тырыш һәм аларны юк итү ягын кара. Ибраһим ибн Әдһәмнең гөнаһ эшләргә теләгән кешегә әйткән сүзләрен һәрвакытта исеңдә тот.

**Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН.**

*("Бәхетлеләрнең серләре")*

***БӘЕТ***

# Ник калдырдың?

*Йөрәк әрнүләрен баса-баса*
*Тормыш сукмагыннан атлыймын.*
*Чишмә булып аккан яшьләремне*
*Туктатырга көчем тапмыймын.*

*Бәгырькәем әрнеп телгәләнә,*
*Җаннарымда әрнү, күз яше.*
*Алып киттең бит син үзең белән*
*Дөньяларның гүзәллеген, бар ямен.*

*Күзем йомсам, ачып карасам да,*
*Илсурымны таба алмыймын.*
*Уйлар, еллар, гомер сукмакларын*
*Кире сүтеп укып карыймын.*

*Алма кебек иде йөрәк парәм,*
*Газиз кешем минем, тиң ярым.*

*Картлык көнебезгә барыр өчен,*
*Бер канатсыз калдым бит, парым.*

*Абынмаска, арып егылмаска*
*Тырышамын хәлдән тайганчы.*
*Кайтарып мин сине яннарыма*
*Карар идем күзем талганчы.*

*Алыр идем йомшак кулларыңнан,*
*Илсурым, дип мең кат кабатлап.*
*Ник калдырдың әрнеп юксынырга?*
*Пар канатсыз барам бит атлап.*

**Лилия ДАУТОВА.**
Нурлат шәһәре,
Татарстан.




**- Мәетне юганда катнашучы җәмәгать өч яки биш кеше булырга тиеш, диләр. Дөресме?**

- Мәетне юарга кергән кешеләрнең азрак булуы яхшырак. Өч яки дүрт кешегә дә керергә рөхсәт ителә. Бу вакытта мәетнең гәүдә авырлыгын да истән чыгарырга ярамый.

**- Мәетне югач, өйдән аягы белән алга каратып алып чыгабыз, ә йорт капкасыннан алып чыкканда, башы белән алга таба күтәреп чыгарабыз. Җеназа намазын урамда укыйбыз. Кайбер галимнәр, капкадан чыкканда да мәетне аягы белән алдан чыгарырга, диләр. Кайсысы дөрес икән?**

- Аяк белән алга таба каратып алып чыгуның аерым мәгънәсе бар. Мәетнең, гадәттә, алда бара торган өлеше астарак була. Шуңа күрә, мисал өчен, баскычтан төшкәндә (шәһәрнең күпкатлы йортларында, авыл йортларының ишегалларында), мәетнең авызыннан кан, су кебек төрле сыекчалар чыгуы бар. Кәфенлекне пычратмау һәм кешеләрне куркытмау өчен, мәетне аягы белән алга каратып чыгаралар. Бу йоланың төп мәгънәсе шул. Кагыйдә буларак, мәет җеназага кадәр аягы белән алга караткан килеш алып барыла, җеназадан соң башы белән алга боралар. Җеназа намазы капкага кадәр укылса, аннан соң башы белән алга таба куеп алып чыксалар да ярый, дип уйлыйм.

**- Әүвәбин намазын кайчан укырга кирәк? Бу вакытта нинди догалар кылына?**

- Әүвәбин намазы – безнең борынгы бабаларыбыз укыган, бик изге, саваплы намаз ул. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтеннән санала һәм ахшам намазыннан соң укыла. Ул нәфел намазы кебек ике рәкәгать укыла. Кайбер китапларда исә 4 рәкәгать укыларга тиеш дип тә язылган. Уку рәвеше – гади нәфел намазы кебек, әмма «әүвәбин намазын укымакка» дип ният кылырга кирәк. Кайбер китапларда, әүвәбин намазының ике рәкәгатендә дә «Әлхәм»нән соң «Аятел-Көрси», өч «әл-Ихлас» сүрәсе укыла, дип әйтелә. Икенчеләрендә, «Әлхәм» сүрәсеннән соң биш «әл-Ихлас» сүрәсе укыла, дип әйтелә.

*("Дин вә йола" газетасыннан)*